Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге составына керүче
Олы Елга авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

13 ноябрь 2025 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 13 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: “Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре), 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, халыкка су бирүне (җибәрүне) тәэмин итүче суэтем башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын, су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- урамнарны яктырту җайланмалары урнаштыру;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- традицион мәет җирләү урыннарын (зиратларны) ремонтлау, төзекләндерү, киртәләп алу.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 588 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 320 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 320 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Олы Елга авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: "Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, халыкка су бирүне (җибәрүне) тәэмин итүче суэтем башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын, су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- урамнарны яктырту җайланмалары урнаштыру;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.
- традицион мәет җирләү урыннарын (зиратларны) ремонтлау, төзекләндерү, киртәләп алу

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16а йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Ф.Ш.Сәйфетдинов